ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ ДЕКАБРЬ * 2020 * КАЗАН

12



Сергей АНДРИАНОВ

4–5 нче битләрне кара

Рашат НИЗАМИ

ШИГЪРИ ШАРЖЛАР

• • •

Минтимер Шәймиевкә

Исемендә "тимер" чыңлап тора,
Җисемендә – татар ныклыгы.
Туган телдә сөйли белгән өчен
Тыңлау рәхәт сине йотлыгып.

• • •

Марат Әхмәтовка

Татар өчен җаны фида аның,
Тарих әйтер беркөн рәхмәтен.
Туган телне яклар өчен кирәк
Марат Готыф улы Әхмәтов...

• • •

Нажар Нәҗмигә

Сорамагыз: кайда туган, диеп,
Кайсы төбәктән ул калыккан?
Фәһем белән язган шигырьләре
Үтә милли, үтә халыкчан!

• • •

Вахит Имамовка

Роман яза, гәҗит нәшер итә,
Күтәрелде Олимп тавына.
Тарих катламнарын актара ул,
Барып җитә Пугач* явына...

• • •

Марсель Галиевкә

Чатыр тавын күккә чөеп мактый,
Йөгерек аның уе, каләме.
Каләменең очларында исә –
Тарих җиле, татар галәме...

• • •

Гәрәй Рәхимгә

Бакчасында агач куаклары,
Яфрак арасыннан җил йөри.
"Бер уч җылы посып ята", – диеп,
Кош оясы тапкан Гөргөри!**

• • •

Рафаэль Хәлилулловка

"Хәлилуллов, хәлең ничек?" – диеп
Һич кенә юк сорап торасы.
Ай саен син "Чаян" журналыңны
Укучыга коеп торасың!

* **Пугач** – Емельян Пугачёв фетнәсенә ишарә.

** **Гөргөри** – паспорттагы исем-фамилиясе Григорий Родионов. Бу керәшен егетен каләмдәшләре, үз итеп, Гөргөри дип йөртәләр.



Александр АЛЁШИН





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел кызыклы мәгълүматка тап булдым. СССР таркалганнан соң долларның безнең рубльгә карата бәясе 40 мең (!) тапкыр арткан икән. Ә бары тик соңгы ел эчендә безнең валюта 25 процентка арзанайган. Ә илебез бит бар нәрсәне дә долларларда сатып ала – телефоннарны, көнкүреш техникасын, кием-салымны, банан, помидорларны да... Хәтта безнең сыерларыбызның сөте дә чит илдә ясалган саву аппараты аша үтә...

Д. ДӘҮЛӘТШИН

ТҮБӘН КАМА

– Нәкъ безнең валюта тотрыклы да инде, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Ә менә долларга бу сыйфат җитеп бетми – ул һаман үсә бирә...**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Акыллы кеше башкалардан аңламый белүе белән аерылып тора.

Бүләкләр, файдалы киңәшләр кебек, бирүчегә генә шатлык китерә.

Халыкара законнар халыкара законнар җыентыгында гына яши.

Пропаганда — үзең ышанмаган нәрсәгә башкаларны ышандыру сәнгате ул.

Дөнья белән яшьләр идарә итә. Картаеп җиткәч.

Мәңге яшәргә тырышып вакытыгызны әрәм итмәгез.

Дәрәҗәлеләрнең шаяртулары һәрвакыт башкаларныкыннан кызыграк.

(зыялылар мәҗлесендә язып алынды)





Ришвәтче гүзәлләр

Гадәттә, коррупция бары тик ирләр эше дип санала. Имеш, калын җилкәле һәм көчле куллы ирләр генә бюджетны кискәләү, кеше бизнесына өлешкә керү һәм зур акчаларны оффшорларга "сөйрәү" белән шөгыльләнә ала. Тик хәзерге үзгәрүчән тормыш моңа зур үзгәрешләр кертә, һәм коррупциянең күп йөзле сурәтендә хатын-кыз образлары төсмерләнә башлый. Гүзәл затлар да, гомуми юнәлештән читтә калырга теләмичә, вак-вак адымнар белән кыек ришвәтчелек сукмагына атлап керә.

Күптән түгел шуның белән Саба районының элекке полиция хезмәткәре капкан. Вакыйга бик гади. Миграция бүлекчәсендә өлкән инспектор булып хезмәт итүче ханым җирле кафеның хуҗасы булган икенче ханымның үзенә эшкә законсыз рәвештә чит ил гражданинын алуы турында ишеткән. Симез калҗа сизеп, инспектор югалып калмаган – 800 меңлек штраф белән куркытып, аннан акча таләп иткән. Соңыннан ул кунакның эшкә законлы урнашуы ачыклана. Акчаны инспекторга... Саба район полиция бүлегенең ашханәсендә тапшыралар. 560 меңнең ришвәтченең кулына керүе белән, аны тоткарлыйлар. Әйтергә кирәк, хәзер ул ханымның җитәкчеләренә дә гамьсезлекләре өчен җавап тотарга туры киләчәк...

Чираттагы тарих Түбән Камада булган. Ростехнадзорның дәүләт инспекторы булып эшләүче ханым предприятиеләр эшен тикшергәндә кагыйдә бозулар тапкан. Штрафларның миллион сумга җитүе мөмкин булган. Предприятиеләрдә үз акчаларына кыйммәтле экспертизалар үткәрү мәсьәләсе дә аның кулында. Ләкин "олы җанлы" тикшерүче аларның хәленә кергән –кагыйдә бозучыларга, зур чыгымнарга бармас өчен, штраф суммасыннан ике тапкыр кимрәк "акчалата бүләк" биреп котылырга тәкъдим ясаган. Шулай итеп, шома хатын изге гамәлләре өчен "рәхмәт" алып кына түгел, кесәсен калынайтып та барган. Бу 20 меңнән 150 меңгә кадәр "бүләк"ләрнең гомуми суммасы миллионга җиткән. Беркетмәләр төзелмәгән, ә башка документлар "тәртипкә китерү" өчен кагыйдә бозучыларның үзләренә бирелгән. Уеннан уймак чыга дигәндәй, эш судка барып җиткән. Әйтергә кирәк, бу исемлек тагын тугыз эш белән тулыланган. Болары инде "рәхмәтле" җитәкчеләргә карата...

Ә хәзер башкала хәлләренә күчик. Яз көне берәү хулиганлык эше буенча изоляторга эләгә. Бераздан адвокаты – 42 яшьлек ханым – төрмәне өйдә утыруга алыштыру мөмкинлеге турында хәбәр сала. Моның өчен бары тик кирәкле кешегә 600 мең сум тапшыру зарур икән. Тик хулиган закон белән мөнәсәбәтләрен тагын да бозарга теләми, һәм бу турыда тиешле урынга хәбәр итә. 600 меңне алганда адвокат кулга алына. Шунысы кызык, бу ханым мошенниклык өчен утыручы адвокатның хәләл җефете булып чыга. Законсыз акча эшләүне уртак бизнеска әверелдергән адвокат гаиләсенең балалары да бар икән. Кечесенә бары тик дүрт яшь...

Шулай да, ришвәтчелек кебек пычрак сазлыкка баткан килеш, Мәскәүдәге таможня посты башлыгы акчаны алган алуын, ләкин бер тиенен дә үзе өчен тотмаган. Ул хезмәткәрләре өчен телефоннар, кәгазь, картриджлар, су сатып алган. Бу исемлеккә шулай ук коммуникатор һәм маршрутизатор да кергән. Бөтен офис "тиген акча" хакына яшәгән. Атаклы Деточкин юлыннан киткән ханымга нинди җәза бирү турында хөкемдарлар озак баш ваткан. Хатын-кыз хатын-кыз булып кала бела. Нәтиҗәдә, хезмәт урыныннан матди файда алу статьясы белән чикләнгәннәр...

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, иҗтимагый челтәрләрдә бу тарихларга карата төрле фикерләр очратырга була: "бичара хатыннар мондый нәрсәгә тормышлары авыр булганга бара", "үзләрен булмаса, балаларын жәлләргә кирәк", "ирләр әнә миллиардлап урлый"... Бер акыллы башы хәтта хатыннар өчен махсус җинаять кодексы булдырырга тәкъдим иткән – йомшак холыклы затлар өчен җәза да йомшаграк булырга тиеш. Ә берсе турыдан-туры ярып салган: алардан тагын нәрсә көтәргә була – алдау аларның канына сеңгән, имеш...

Әлбәттә, аларның бөтенесенең дә гаиләләре, балалары, оныклары бар. Шуңа күрә бёз аларның исемнәрен атамыйбыз да – хурлыгы болай да җитәрлек... Ә икенче яктан карасаң, хәтта ирләр дә муеннарын сындырган кыек юлга басканда – алар якыннары турында уйладылар микән?.. Юктыр. Менә шуңа күрә эшләрен, иптәшләренең ихтирамын югалтып, алар урынына мәңге юылмас "ришвәтче" исемен алдылар да инде.

Людмила САФИУЛЛИНА



Илдар НӘФИЕВ

Игорь КИЙКО





Михаил ЛАРИЧЕВ



Виталий ФЕОКТИСТОВ

Агай-эне, ак мыек...

Революциягә кадәрге дворян-морзалар турында сөйләшкәндә, аларны ул чактагы җәмгыятьнең иң затлы катлавы, зыялы өлеше итеп күзаллыйлар. Мәрмәр залларда Шуберт вальсы яңгырый, зифа чибәрләр офицерлар белән искиткеч биюләр башкара, лакейлар йөгерешеп йөри... Ләкин бу гүзәл манзараның арткы ягында башка күренешләр дә чәчәк аткан – алдау, ришвәт, сатлык судлар һәм әшнәлек. Иске Рәсәйнең алдынгы өлкәләренең берсе – Казан губернасы да моннан читтә калмаган, әлбәттә. Менә ул чакта "зыялы әфәнделәр" тарафыннан кылынган кыңгыр эшләрнең берничәсе...

1873 елда Чистай өязе идарәсе җитәкчесе Н. Рыбушкин җирлек юлларында күперләр ремонтлаган оешманы "төп башына утырта" – башкарылган эш өчен тиеш акчаны түләми. Земство җыелышы эшне судка тапшыра. Нәтиҗәдә, Н. Рыбушкин "хезмәт буенча тапшырылган акча суммаларына саксыз караган өчен" эшеннән алына.

Тагын бер охшаш тарих азык-төлек белән тәэмин итү – урлашу өчен иң уңай өлкә белән бәйләнгән. Шуны истә тотып, хакимият монда тикшерелгән һәм абруйлы, моңа кадәр сәүдә белән шөгыльләнгән кешеләрне куярга тырышканнар. Ләкин бу чарлар да ярдәм итмәгән, чөнки андыйларның эшчәнлеге еш кына тикшерүкүзәтүсез калган. 1900 елда Спас өязендә нәкъ шулай булган да. 30 мең пот он сатып алу буенча контрактны өязнең иң нык хуҗалыкның иясе, җирле дворяниннар җитәкчесе В. Колбецкийга тапшырганнар. Акчаны алганнан соң алпавыт әфәнде алган йөкләмәләрен үтәмәгән. Бу эш аулак рәвештә генә каралган. Законсыз акча үзләштергән өчен җитәкче морза штрафка тартылган һәм эшеннән колак каккан.

1908 елда «Камско-Волжская речь» газетасында бер мәкалә басылып чыга. Анда Казанга күчеп килгән элекке Саратов губернасының земство башлыгы Геркенның казна акчалары белән "ирекле эш итеп" алты мең сум үзләштерүе һәм җавапка тартылмый калуы турында сүз бара. Тикшерү алты ел буе дәвам итә, җитди финанс җинаятьләрендә гаепләнүче берни булмагандай элекке эшендә хезмәт итә бирә. Каракны нинди җәзага тартылуы мөмкин булган соң? Каты шелтә, йә "өч айдан бер елга кадәр акча тотып калу", йә эшеннән азат итү. Шулай да Геркен эшеннән чыгарыла, ләкин соңыннан амнистиягә эләгеп, дәүләт хезмәтен дәвам итәргә мөмкинлек ала.

Һәм бөтенләй гаҗәеп хәл Казан һәм Царекокшайк өязләренең дворянннар җитәкчесе Г. Горталов белән була. Ул үзенең ярдәмче секретарена шулкадәр ышана ки, тегесе шәхси бюджетын утыз мең сумга тулыландыру мөмкинлегенә ирешә. Бурычны Горталов үзе кайтарып бирә, ә шук ярдәмчене Себергә озаталар. Арестантларның юлы Горталов утары яныннан уза. Хуҗа конвой башлыгы белән сөйләшенеп, гаепне үз өстенә алган секретарьны йортында кабул итә – мунчада юындырып, ашатып-эчертеп, чираттагы этап ноктасына илтеп куя...

Күргәнебезчә, "үз кешеләрен" гаепләренә йомшак карау дворян-морзалар арасында киң таралган булган. Нәкъ безнең караклар заманындагы үзләрен "яңа морзалар" итеп тойган түрә мошенникларның, үзләренең затлы сарайларыннан чыкмыйча да, шартлы срок йә амнистия алып, урланган миллиардлары өстендә утырып калганнары шикелле...

Рөстәм ХАЛИТОВ

Виктор БОГОРАД



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Наталья БАХТИНА


АК БӘХЕТЛӘР СЕЗГӘ!

Күпме Яңа ел үткәргәнмен икән үз гомеремдә? Очына чыгып булмый... Вакыт уза тора, бәйрәме шул ук, ә каршылавы һаман төрлечә... Мәсәлән, яшь чакларны алыйк. Ун студент җыелабыз, бер шешә портвейн, бер кисәк сыйр, ярты ипи – барыбыз да бәхетле. Бераз олыгайдык, эшли башладык, өйләнештек. Чын Яңа ел өстәлләре, әллә ни мулдан булмаса да, шатлыгы күпме! Йә космоска очканнар, йә Американы менә-менә куып җитәбез, йә котыпта кукуруз чәчәргә җыенабыз. Торгынлык елларын әйтеп торасы да юк – ел буе бер банка яшел борчактан күзең алмыйча, авыз суларыңны агызып бәйрәмгә әзерләнәчәк "Оливье" салатын көтәсең. Аннан соң перестройка талоннары: «Кагылма, бу – Яңа елга!» Ә кибетләр бәяләре якын килеп булмый торган продуктлар белән тулгач, Яңа ел алдыннан өч нәрсәдән курка идек – дефолттан, чираттагы реформадан һәм чакырылмаган кунаклардан. Нефть акчасы ага башлаган еллардагы корпоративлар – монысы инде бөтенләй башка җыр...

Ниһаять, минем урамга да бәйрәм килде. Мин дә Яңа елны кешечә, киң итеп, байларча каршылый алам. Дусларым Интернетта фотоларын курга яраталар. Кем Эйфель манарасы янында, кем диңгез лайнерында, кем Кипр комлыкларында... Ә мин менә фатирымда фотога төшәрлек почмак күпме эзләдем, таба алмадым. Йә стенаның обое купкан, йә диванның дүртенче тәпие урынына Маркс томнары куелган. Ләкин болар инде артта калды. Бу юлы күп итеп кунак җыям. Кунарга калсалар да, бүлмәләр җитәрлек. Аларга мәрмәр стеналы банкет залын, коньяк җимешләре үсә торган кышкы бакчамны күрсәтәчәкмен, картиналар галереясын... Дусларымның көнләшүдән шартларга җиткән сары йөзләренә рәхәтләнеп карыйм әле. Кунакларны кайда каршылауны да алдан уйлап куярга кирәк булыр. Бәлки, яңа тунымны һәм өске ягына елмайган авыз ясалган саклау маскасы киеп баскычка чыгып басарга һәм колоннага сөялергәдер?

Абрамовичның затлы сарае фотосына үземнең гәүдәмне куя алдым бугай. Ә калган нечкәлекләрен оныгым җиренә җиткереп бирер әле. Ул фотошопны миннән күпкә яхшырак белә.

Ә инде чынлап әйтсәк, ак бәхетләр телим сезгә! Барыбер өебездә шампанский, мандариннар һәм чыршы булачак бит. Тәм һәм исне тою бәхетеннән генә мәхрүм булмаска иде. Кыш бабайдан бүләккә шуны сорарбыз...



Игорь КИЙКО



Александр АЛЁШИН



• • •

Бер депутат икенчесеннән сорый:

– Ни өчен безне берәү дә яратмый икән?

– Мин дә шуны аңламыйм, югыйсә бернәрсә дә эшләмибез бит инде...

• • •

Яңа йортта яшәячәк кеше прорабтан сорый:

– Өйнең стеналары бик юка түгелме?

– Борчылмагыз, аларга әле обой да ябыштырасы бар ич.

• • •

– Әбекәй, нигә инде ул пакетларны юасың? Егерме беренче гасыр бит дөньяда! Юкка су әрәм итәсең, һәм ваннаны алып торасың!

– Ярар, ярар, балакаем. Хәзер бушатам. Ю үзеңнең бер тапкыр куллана торган битлекләреңне.

• • •

– Официант, сез нигә исерек клиентларга сыра китерәсез?

– Нишлим соң? Аеклары безнең сыраны эчми бит.

• • •

– Карале, сиңа бурычка ике мең биргәннән бирле син мине танымамышка салынып йөри башладың. Хәтта исәнләшмисең дә.

– Нәрсә, шул ике меңне алыр өчен алдыңда шулхәтле түбәнсенүем җитмәдемени?

• • •

Караңгы тыкрыктан култыклашып икәү бара. Кинәт каршыларына өч әзмәвер килеп баса:

– Тартырга бармы?

– Кадерлем, йөгер!

– Үзең йөгер! Нишләп соң әле сигарет артыннан булса, гел мин чабарга тиеш?..

• • •

– Доктор, нишләп бөтен табибларның язуларын танып булмый? Менә монда нәрсә язган идегез сез?

– Облитерирующий эндартериит, пароксизмальная тахикардия, дисциркуляторная энцефалопатия.

– Шайтан алгыры, сезнең әйтүегез дә язган кебек икән!

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

ТУЙ КҮЛМӘГЕ

Ертылды күлмәк терсәктән,
Кәчтүмнең җиңе тузды.
Чалбар балагы сидрәде,
Шактый күп вакыт узды...

Күп су акты без өйләнгән,
Парлашкан көннән башлап.
Юкка әйткәнмени Тукай:
"Шайтанны булмый ташлап!"

Ике бала тапты хатын:
Тукландыр да киендер,
Артык калса аналарын
Бүләклә һәм сөендер!

Әби-бабай янына кайт,
Күчтәнәчең кыстырып.
Соңгы тиенеңә кадәр
Бетер шулай туздырып.

Анда кайткач та тик ятма –
Бакчага чык, бөк билең.
Өйләндең, кияү булдыңмы –
Язмышың шушы синең!

Ә хатынның туй күлмәге
Бер тузмаган, шул көе.
Сәдәфе дә һич төшмәгән,
Һәм сүтелмәгән җөе.

Кунса кунган, күя түгел,
Бары шкаф тузаны.
Сабыр гына көтә бугай,
Минем йончып тузганны.

Ә мин кулга инә алып
Тегү серен өйрәнәм:
Туйда кигән киемнәргә
Ямау салып җибәрәм.

Хатынны да шулай итеп
Бирер идем кияүгә.
Күлмәге өр-яңа да бит,
Үзе очсыз бәядә.

ҮЗЕМНЕ ТАНЫЙ АЛМЫЙМ

Бар иде лә чаклар!
Киң болында
«Мине ал» дип торды һәр гөле –
Йөзәр тапкыр бер көн эчендә без
Гашыйк идек, Мәҗнүн шикелле...

...Соңгы вакыт нидер үзгәрде күк,
Аңлый алмыйм һич тә үземне.
Кызлар күргәч,
Йөрәк шашып типми,
Читкә борам никтер йөземне.
Алтмыш тулды бары...
Яшьлек дәрте
Беркая да юкса, китмәде –
Әллә магнит кыры тыныч түгел,
Әллә глобаль җылыну хикмәте...

Ринат АБЗАЛОВ

Вячеслав ШИЛОВ



Дамир МОРТАЗИН

Шаккатырлык хәл бит!..

Миңа урамда бер хулиган бәйләнде. Теләсә нәрсә әйтеп хурлады да, пычрак суга этеп, кулымдагы бәрәңгеле букчамны тартып алды. Мин аңыма килгәнче, качарга да өлгерде. Мин баткан җиремнән чыгып, полициягә шалтыраттым. Үзем: "Барыбер эзләмәячәкләр..." – дип уйлыйм. Күп тә үтмәде телефонымнан хәбәр бирәләр: сезне кыерсыткан бәндәне тоттык, гариза языгыз да, бәрәңгегезне алып китегез. Шаккатырлык хәл бит!

Кичен күрше белән сөйләшәбез: "Шул гынамы?" – ди бу миңа. – Иртә белән машинамда эшкә барам. Куак артыннан бер гаишник атылып килеп чыкмасынмы. Минем инде, гадәттәгечә, йөз тәңкалек әзерләнеп куелган. Ә ул документларымны гына тикшерде дә, матур гына елмаеп, хәерле юл теләп калды. Үзең беләсең, кайчан гаишникларның штрафсыз җибәргәннәрен?! Шаккатырлык хәл бит!

Күрше белән бу сәер полицайның тәртибен тикшереп бетерергә өлгермәдек, эшеннән хатын кайтып керде. "Заводта шатлык – ниһать хезмәт хакы бирделәр, җитмәсә, тоткарлаган өчен процентлары белән. Директор гафу үтенде, хәтта..." – ди.

– Ну, шыттырасың да инде! – дип гаҗәпләндек без. "Икмәктер, чып-чын дөрес!" – дип ант итә башлады хатын, өстәлгә акчаларын җәеп. Шаккатырлык хәл бит!


Озакламый институттан кыз кайтты. "Имтиханыңны бирдеңме? – дип сорыйбыз. "Бишле"гә! – ди. "Ничек алай? Без бит акчаны өчле өчен генә бирдек?" "Безнең укытучы хәзер билгене белем өчен генә куячагын әйтте! Һәм кисәтеп тә куйды, моннан соң зачеткагызга бернинди акча кыстырып бирүегезне күрмим... – диде.

– Шаккатырлык хәл бит! – дип хатын кулларын җәеп җибәрде. – Дөньяда ниләр генә булмый? Кешечә яши башладык микән әллә?

Дөньяда нинди могҗизалар туганын кичен телевидениедәге яңалыклардан аңладык. Үзәктән бер төркем прокурорлар килгән икән шәһәребезгә. Исәпләре: погонлы угрыларга, ришвәтче түрәләргә җинаять эшләре ачарга – еллар буе эшләгән акчаларын ала алмый газаплана бит хезмәт халкы. Менә шундый генераль юнәлеш барлыкка килгән ди.

Димәк, кешечә яши башлаячакбыз! Ай буе, Аллаһу теләсә. Аның амин дигән чагына туры килсә, бәлки, ике ай буе...







Абау!

ҮЗЕМ ХУҖА

Чаллыдагы «Пассажирлар йөртү» предприятиесе автобус йөртүчеләрнең юл кагыйдәләрен бозуы өчен үз штрафларын кертергә булган. Директор Николай Тютяшкин маршрут автобусларын видеорегистраторлар белән җиһазлау урынына үзе шәһәрнең юл чатларына чыгып, хезмәткәрләренең эшен күзәтеп тора икән. Тәртип бозучыларын премиядән мәхрүм итәләр. Автобуслар башлыгының ысулларын ЮХИДИда өнәмәгәннәр: юл хәрәкәте уяу шәхси контрольгә куелуга карамастан, автобуслар катнашы белән булган юл очракларының саны 17 процентка арткан.

УҢЫШСЫЗ ОПЕРАЦИЯ

Казанда яшәүче берәү, наркотиклар таратучыны тоту максаты белән, полицейский формасына киенеп чыккан. Әмма "махсус операция" барышында үзе хокук сакчылары кулына эләккән. Ялган полицейскийның кесәсендә тыелган матдәләр табылган. Токарланучы каршы килеп тормаган, һәм чын полицейскийларга үзе аулаган "объект"ны тапшырган. Анысының кесәсендә дә наркотиклар тапканнар.

ИНТЕРНЕТТА СҮГЕНҮ

Татарстанда беренче судта тапкыр Интернет-чатта мәсхәрәләү турында эш каралган. Казан йортларының берсендә яшәүчеләр торак хуҗалары иптәшлегенә кучу турында бәхәсләшкәндә артыгын кызып киткәннәр. Бер кайнар канлы ханым әңгәмә вакытында ир кешегә тел нормаларына сыймый торган сүз белән мөрәҗәгать иткән. Тегесе, озак уйламыйча, "әңгәмә"нең копиясен алып, прокуратурага киткән. Лингвистик экспертиза кулланылган сүзнең ир кешенең абруен төшергән дип тапкан. Интернетта сүгенгән хатынга суд мең сум штраф салган.

ШОМА ПРИСТАВ

Бөгелмәдә бер суд приставы бурычлы гражданнарның мәсьәләләрен үзенчә хәл иткән. Ул алардан акча алып, түләү квитанциясе биргән. Ләкин бу акчалар кассага барып җитмәгән, ә квитанцияләр ялган булып чыккан. Шулай итеп, мошенник пристав өч ел буе бурычлы гражданнарны һәм хезмәттәшләрен алдап йөргән. Аның "эшчәнлеге" казнага 100 мең сумнан артык зыян китергән.

Рамил ИСЛАМОВ

КАЛГАНЫН ҮЗЕГЕЗ АҢЛЫЙСЫЗДЫР...

– Узыгыз, узыгыз! Утырыгыз! Тыңлыйм сезне, хөрмәтлем... Ах, бер минутка сабыр итегез, шалтыраталар! Алло! Әйе, әйе, бу – мин! Нәрсә, төзелешкә подряд? Тиешле хак өчен алынган йөкләмә бит ул... Бу архикатлаулы сорау... Кыргый конкуренция... Тендер үткәрергә кирәк... Ярар, ярар, сезнең белән күп еллар уңышлы мөнәсәбәтебез хакына нәрсә булса да уйлап табарбыз... Калганын үзегез аңлыйсыз бит инде...

Ах, тагын шалтыраталар! Тыңлыйм... Пардон. Әйе, бу мин! Нәрсә, сезнең материалларны сатып алырга? Андый эшләр Вәли Галиевичның үз карамагында! Хәзер хәлләр катлаулырак! Безнең белән хезмәттәшлек итәргә теләүчеләр бик күп... Шул, сезнең өчен генә дип тырышсам инде... Калганын үзегез аңлыйсыздыр...

Әйе, тыңлыйм сезне! Гафу итегез, тагын телефон – эшләргә ирек бирмиләр! Әйе, әйе, мин! Акча табу кыен?.. Белмим инде, ничек ярдәм итәргә дә... Баш күтәрми эшлибез бит – ревизорлар, аудиторлар, контролерлар... Ярар, тырышып карармын, сезнең хөрмәткә генә... Калганын үзегез аңлыйсыздыр...


Җен алгыры, тынгы бирмиләр, шалтыраталар бит һаман! Әйе, мин! Нәрсә? Безгә эшкә керергә? Мөмкин хәл түгел! Штатларны кыскарту бара... Шул, үзем ныклап тотынсам гына инде... Калганын үзегез аңлыйсыздыр... Ну инде, тыңлыйм дим игътибар белән!

– Мин шәһәр газетасы редакциясеннән. Без сезнең белән әңгәмә оештырырбыз дип сүз куешкан идек.

– Әйе, әйе, хәтерлим, хәтерлим... Нәрсә турында диешкән идек әле?

– Сезнең оешмада ничек итеп ришвәтчелек белән көрәшү турында.

– Алайса, языгыз.. Безнең оешма ил белән бергә бу көрәшкә күтәрелде. Үзегез беләсез, ул – рак шеше кебек... Җаныбызны кимерә...




Игорь КИЙКО

карантин кәртинкәләре

Валерий ТАРАСЕНКО



Александр КОСМЫЛИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Сергей АНДРИАНОВ



Гүзәл НӘБИУЛЛИНА



– Кадерлем, – диде хатыны, – онытмадыңмы әле, тиздән Яңа ел җитә бит. Бәйрәм өстәленә нәрсәләр куябыз инде? Көтмәгәндә кунаклар да килергә мөмкин бит.

– Алай булгач нишлибез, – дип куйды ире, телевизор каравыннан аерылмыйча. – Әйдә, әйтеп тор.

Хатыны кәгазь-каләм алып, язарга тотынды:

– Минемчә, салатлардан тотынырга кирәк. Оливье. Ярыймы? Әйбәт ич?

– Оливье? Хмм... – ире уйга батты. – Кишер үзебезнеке. Файдалы. Салатка бәрәңге дә кирәктер... Юк, юк. Анда крахмал. Ул зыянлы. Аны бит әле майонез белән болгатырга кирәк. Анысы, гомумән, сәламәтлеккә ярый торган нәрсә түгел.

– Аңлашылды, – диде хатыны. – Итнең ниндиен әзерлибез?

– Ит? Безнең яшьтә кызыл ит ашау бик зыянлы. Тавык ите антибиотиклар белән дыңгычланган. Дуңгыз...

– Әйтмәле шуның сүзен, татар башың белән. Хәләл колбаса алыйк. Теге – матур итеп киселгәнне.

– Фу... Химия.

– Хәләл булсадамы?.. Кадерлем, торт-мазар куйсак табынга, ә? Ичмасам, ул бизәп торыр бәйрәм өстәлен.

– Син, нәрсә??? Анда бит гел Ешкалар! Шуның белән агуланасың киләме әллә?

– Соң, нәрсә әзерлибез? Ничек итеп Яңа елны каршылыйбыз?

– Менә ничек. Файдалы ризыклар белән. Ипине үзең пешерерсең. Ул бик тәмле килеп чыга синең. Чәйне үзебезнең бакчада үскән үләннәрдән ясарбыз.

Менә шул. Бернинди химия дә булмаячак. Бары тик файдалы, шифалы, тәмле ризыклар белән генә сыйланачакбыз һәм кунакларны да сыйлаячакбыз.

КРАСНОДАР ХЛЕСТАКОВЫ

"Ревизор" комедиясе сюжетын Козлов атлы берәү кабатлаган. Ул көтмәгәндә тикшерү белән Краснодар краеның Передовая станицасына килеп төшкән. Үзен край администрациясе хезмәткәре дип таныштырган, кешеләрнең эшләре белән кызыксынган. Җирле түрәләр кунакны өч көн объектлар буйлап йөрткәннәр һәм аның начар сүзләр белән җиткерелгән каты тәнкыйтен тыңлаганнар. Җирле проблемаларга мондый караш хуҗаларда шик тудырган. Хезмәттәшләренә шалтыратып, край администрациясендә Козлов исемле хезмәткәрнең беркайчанда булмавын белгәннәр. Бераз телсез торганнан соң, соң Краснодар Хлестаковы җитез генә табан ялтыраткан.

ӘКИЯТИ УРЫН

Вологда өлкәсенең Кыш бабай биләмәләрендә чып-чын финанс җәнҗаллары башланып киткән. Аудиторлар "Дед Мороз" ачык җәмгыятен тикшергәч, оранизациянең 2019 елдагы чиста кереме алдагы ел белән чагыштырганда өч мәртәбә кимегән һәм чиста зыян 21 млн. сумны тәшкил иткәнен ачыклаганнар. Бу вакытта Великий Устюгта туристлар агымы хәтта арткан да. Финанс документлар әкияти ысул белән алып барылганын күргәч, бабайның әкияти йортын җитәкләүче Муромцева Татьянаны нәфис кулларыннан эләктереп алганнар.

ЯШЬЛЕ БӘЙРӘМ

Томск шәһәренең ритуал конторасының хуҗасы Александр Шарабаев илдә яңа бәйрәм – кеше күмүчеләрнең көнен кертергә тәкъдим иткән. Бу өлкәдә хезмәт итүчеләрнең профессиональ бәйрәмнәре юк икән, ә анда исә 40 мең россияле эшли. Ул артыгын баш ватмый гына, бәйрәмне Хэллоуин алдыннан билгеләргә уйлый икән.

КОКОС БЕЛӘН ТҮЛӘҮ

Балидагы студентлар көллияттә укыган өчен "натура" белән түләргә рөхсәт иткәннәр. Пандемия сәбәпле, студентларның түләү мөмкинлеге бөтенләй юкка чыккан. Башта көллияттә ваклап түләү системасы һәм ташламалар кертеп караганнар, ә аннары, гомумән, укыган өчен кокослар белән түләргә тәкъдим иткәннәр. Көллияттә кокос мае ясыйлар, шуңа күрә чималны барыбер сатып аласы бар бит. Хәзер бер семестр өчен студентка 10 мең кокос алып килергә кирәк булачак.

Боз бизәкләре





Мирзаһит тормышыннан

БӘРӘҢГЕ АЛУ

Көз. Әбиләр чуагы. Аяз, кояшлы көннәр тора. Уңыш җыярга менә дигән вакыт! Мирзаһит, җиңен сызганып, улын бәрәңге казырга өйрәтә.

– Көрәгеңне сабактан ераграк керт, тик кыйгачлап түгел – туп-туры итеп! Бәрәңгесе киселерлек булмасын, – дип сөйләнә ул.

Ләкин Айнур шунда ук зур кызыл бәрәңгене нәкъ урталай кисеп ташлый. Арттан чиләк тотып әнисе бара – "халык контроле". Бу хәлне күреп, ул сукранырга тотына:

– Карале, Мирзаһит, улыңны юньләбрәк өйрәт инде, алайса бөтен бәрәңгене турап бетерәсез бит!

– Ярый, хатын, артыгын шаулама, – ди Мирзаһит. – Нечектер өйрәнергә кирәк бит инде.

Нәкъ бер секундтан ул киселгән бәрәңгенең икенче яртысын кулына ала һәм тагын сүгенә башлый:

– Ю-ук!.. Начар эшләгән өчен штраф чәпемичә булмый сезгә!

– Тынычлан инде, хатын, – дип җавап бирә Мирзаһит. – Бер киселгән бәрәңге өчен ике тапкыр ачуланмыйлар инде!

Бераздан Айнур әйбәт кенә казый башлый – әтисенең дәресләре бушка китми. Кичкә кадәр эшлиләр болар, ә иртә таңнан Мирзаһит пилорамасына эшкә китә. Ярдәмчесен күрү белән үзенә чакырып китерә:

– Васыйф, анда машина килгән, бушатышырга кирәк. Исеңдәме, соңгы тапкыр бөтен такталарны миңа өрмиадан өяргә туры килгән иде? Кара аны, игътибарлырак бул, минем йөзгә кызыллык йөгертәсе булма!

– Ярый инде, Мирзаһит абый, булган нәрсә булган, – ди Васыйф, күз кысып. – Бер киселгән бәрәңге өчен ике тапкыр ачуланмыйлар!

Мирзаһит моңа бик гаҗәпләнә:

– Каян беләсең син моны?! Койма артыннан тыңлап тордыңмы әллә?

– И, моны бөтен авыл сөйли ич инде, – ди Васыйф. – Үзең күрәсең, бәрәңге казу вакыты бит!

Мирзаһит кулын гына болгап куя – сиңа үз сүзләрең белән җавап бирәләр икән, берни дә әйтеп булмый.

КЛАССТАШ

Берзаман авылга күптәннән шәһәрдә яшәүче Мирзаһитның классташы кунакка килеп төшә. Иске дустына да кыгылып чыга бу. Сөйләшеп утыралар, гамьсез бала чакларны, маҗаралы яшьлекләрен искә алалар.

Классташы шәһәр тормышы турында сөйли башлый.

– Шәһәрдә тормыш җиңелдән түгел. Уйлап кара: балалар бакчаларында урын җитми, бала туу белән чиратка басарга кирәк – ә файдасы юк! Мәктәпкә эләгү җиңелрәк анысы, ләкин баланы беренче сыйныфка әзерләргә күпме акча кирәк! Ә авырып китүдән Аллам сакласын – ыштансыз калырсың! Эш турында әйтеп торасы да юк – яхшы урынга урнашыр өчен күпме чабарга кирәк. Ә зиратлар? Анда да урын юк! Теге дөньяга да урыннар алып куелган!

– Кадерле дустым, – дип елмаеп җавап бирә Мирзаһит, кала моң-зарларын тыңлап бетергәч. – Кайт авылга. Балда-майда йөзмәссең, әлбәттә, ләкин без сине кешечә җирли алырбыз. Вәгъдә бирәм!


Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ







Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 12, 1992



– Вәт житте заман! Барысына да тылсымлы ашьяулык кирәк...

Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 18, 1992

ШӘЙМИЕВ ФАТИРЫ

Язмамны Шәймиев фатиры дип атарга булдым. Ник дисәгез, хәзер аңлатырмын.

Туганнан бирле мин Борисково бистәсендә яшәдем. Үз йортыбыз бар иде, хуҗалык. Әтием исән чагында йортны ул карап торды. Ләкин 45 яшендә әтием авырып вафат булды. Өйдә хатын-кызлар гына калды. Алай да, тырыштык. Кышларын өебез бик җылы булмаса да, тату яшәдек, туңа башласак, ишегалдына чыгып, кар көрәдек, тиргә батып керә идек. Шулай җылындык.

Минем ул елларда кечкенәдән килгән бик яраткан хоббием бар иде. Һиндстан биюләре. Һинд киносы. Бу мәхәббәт мине "Сантош" бию ансамбленә алып килде. Һәм озак еллар аның җитәкчесе булырга да туры килде. Сценарий язып, концертлар алып бардым. Шуның белән өйдәге салкын бүлмәләр онытылып та тора иде.

Бервакыт, 9 Майда, безнең ансамбльгә ул вакыттагы беренче Президентыбыз – Минтимер Шәймиевне каршы алырга куштылар. Очрашу бик матур үтте, фотога да төштек.

...Безнең урамны ел саен су баса башлагач, без, күршеләр белән җыелышып, заявлениеләр язып, кая барырга мөмкин, шунда йөрдек. Ярдәм сорап. 90 нчы еллар иде бу. Ни дисәң дә, биеп кенә тормыш бармый бит...

Шул елларда М. Шәймиев программасы чыкты. "О переселении ветхого жилья" дигән. Ходай рәхмәте белән безнең урамны да шул программага кертсәләр, яхшы булыр иде. Тагын йөрибез, тагын язулар җыябыз. Тәки керттеләр бит безне шул программага. Әллә 98 әллә 99 нчы елга... Язулар таратып чыктылар.

94 елны өйгә комиссия килде. Әнием өйдә берүзе булган. Без эштә. Кергәннәр, караганнар... Әйе, йортның рәте юк.

Шуннан килүчеләрнең берсе әйткән әниемә:

– И, апа, күреп торабыз инде йортыгызның хәлен. Тик бераз көтегез инде. Андый йортлар Казанда бик күп бит.

Комиссия кухня аша чыгып барганда, берсенең сервантта торган фотога күзе төшкән:

– Абау, карагыз әле, Шәймиев фотосы бит монда. Каян килде ул сезгә? – дип сораган.

– Аның сул ягында минем кызым басып тора, – дип әйткән әнием.

Тегеләр аптырап калган:

– Кызыгыз шул тирәдә йөреп, фатир ала алмыйсызмы?

– Бар кешегә дә ул фотоны күрсәтеп, безгә фатир бирегез дип әйтеп булмый бит инде.

Комиссия кешеләре чыгып китә.

Бер-ике көннән соң капка кагалар. Чыксак, безнең райисполкомнан килгәннәр икән. Әнием килеп керде өйгә: үзе елый, үзе көлә:

– Кызым, әйдә, тиз генә җыен, райисполкомга чакырдылар, безгә фатир бирәләр.

Сөенгәнебезне белсәгез иде шул вакытта. Шулай итеп, Яңа елны без яңа йортта, җылыда каршы алдык. Чыннан да, Минтимер Шәрипович биргән фатир булып чыкты бит инде бу. Рәхмәт яугыры.

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

Василий АЛЕКСАНДРОВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

2021 елны каршылау бәйрәмен 2020 елның бетүе бәйрәменә алмаштырыру дөрес булыр иде.

• • •

– Хәзерге яшьләр оятсыз, вөҗдансыз.
– Ә элек ничек иде?
– Элек без шундый идек.

• • •

– Доктор, ирем мине канәгатьләндерми башлады!
– Бу нәрсәдә чагыла?
– Аның минем шау-шу куптарырга маташуыма исе дә китми!

• • •

– Чегән минем яшь чагымда күп акча күрәзәлек итте.
– Алдагандыр?
– Юк, инде менә егерме ел буе кассир булып эшлим.

• • •

"Саклanганны Алла саклый да", – дип башлады эшен Үлемсез Кощей, супермаркетка кергәндә, маскасын һәм перчаткасын кия-кия.

• • •

– Миңа иртәгәгә кадәр мең сум биреп тора алмыйсыңмы?
– Бирә алам. Ләкин иртәгә кайтармасаң, миннән беркайчан да бер тиен дә ала алмаячаксың!
– Алай булгач, биш мең итеп бир инде...

• • •

– Бу попугаегыз күпме тора?
– Әйтә алмыйм. Бәясе турында үзе белән сөйләшегез.

• • •


Һәрвакыт чираттагы түрәгә җинаять эше кузгатылган саен, шаклар катам – кирәк бит шулхәтле урларга, хәтта үз кешеләре бер фикергә килә – туймас җан.

• • •

– Мин синең чын йөзеңне ачарга телим.
– Булдыра алмыйсың, хәзер маскасыз йөрергә ярамый.

• • •

– Сезнең Интернетыгыз тиз уйлыймы?
– Бик тиз уйлый, хәтта акча түләп өлгерә алмыйм..





...КЫЗЫЛ КАР ЯУГАЧ...

«Чаян» дус! Казан яны Куюки бистәсендәге "Светлый" Торак комплексында бик күп балалы яшь гаиләләр яши. Ә менә балалар бакчасы монда бераү генә. Икенчесен дә төзи башлаганнар иде, нигәдер, төзелешне туктаттылар. Күптән түгел аның сүтеләчәге дә билгеле булды. Аптырашта калган әти-әниләргә моны болай дип аңлаттылар: борчылырга сәбәп юк, ул бакча барыбер коммерция нигезендә эшләячәк һәм барлык ипотекачылар аны күтәрә алмаячак, дип. Шуңа күрә төзүче компания рентабельле булмаган бу төзелешне туктаткан һәм аның урынына яшәр өчен йортлар торгызырга уйлаган. Шулай да соңрак тынычландырганнар: тора-бара монда ике балалар бакчасы һәм мәктәп калкып чыгачак икән, бюджетка корылган һәм һәр гаилә өчен кулай. Хәзер эш юктан гына тора – финанс табудан, урынын билгеләүдән, проект эшләүдән һәм бөтенесен килешүдән... Беренче балалар бакчасы сафка кертү киләсе елга планлаштырылган. Безгә шуңа ышанырга һәм көтәргә генә кала, ә бит мәгълүм мәкальдә башкачарак әйтелә түгелме соң?..

М. ЮНЫСОВА

КУЮКИ


ЧҮП – ВАК МӘСЬӘЛӘ ТҮГЕЛ


Кадерле редакция! Соңгы вакытта без муеннан бурычка баткан халыкка әйләнәбез ахрысы. Кешеләр барысына һәм һәркайда бурычлы – дәүләткә, салым органнарына, банкларга, ЖКХга, мәктәпкә, тормыш иптәшләренә... Ә безнең бистәдә яшәүчеләр чүп җыю мәшгульлеге белән шөгыльләнүчеләр өчен дә.

Узган елгы гыйнвар аеннан бирле безгә ТБО (твердые бытовые отходы) чыгарган өчен квитанцияләр килми башлады. Үзләрен җаваплы тойган кешеләр бу мәсьәләгә ачыклык кертүне теләп, бистә хакимиятенә агылдылар. "Барысы да закон кушканча эшләнелә", – дип аңлатылды аларга. Илдә чүп реформасы үткәрелә, менә үзгәрешләр кертелгәч, җайга кергән түләүләр дә кайтыр... Вәгъдә ителгән үзгәрешләр безгә ел ярымнан килеп җитте. Нәтиҗәсе – чүп капчыгы белән башка суккан кебек! Һәр йорт һәм фатир чүп чыгарган өчен 5 тән алып 15 меңгә кадәр бурычлы. Бу очракта хакимияткә хәтта үзләрендә җаваплылык сизмәгән кешеләр дә атылдылар: "реформаторлар" белән договорлар юк, бурычлар каян килгән? "Барысы да закон буенча", – дип, үз сүзләрен кабатлады түрәләр. Баксаң, 2019 елның гыйнварыннан УК "ПЖКХ" үз сайтына барлык кешеләр белән дә автомат рәвештә үзгәрешләр кабул ителә дигән күмәк договор куйганнар икән. Ә ни өчен бу вакыт эчендә бистә кешеләре квитанцияләр алмаган? Хакимияттә дә, УКда да бу мәсьәләгә ачык җавап бирмәделәр, ләкин искәрттеләр, законнарны белмәү – чүп җаваплылыгыннан арындырмый.

А. ЗАРИПОВА

ВАСИЛЬЕВО





Әхмәт Исхакның тууына – 115 ел



Быел күренекле татар шагыйре, тәрҗемәче һәм публицист Әхмәт Исхакның тууына 115 ел булды.

Атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, Татар педагогика техникумын тәмамлагач, ул Мәскәүгә укырга җибәрелә. Анда күренекле әдипләр, бигрәк тә Муса Җәлил белән якыннан аралаша. Мәскәүдә Үзәк нәшриятта басылган беренче китабыннан соң ул талантлы шагыйрь булып танылa.

Әхмәт Исхак 1963–67 елларда «Чаян»ның баш редакторы булып эшли. Күп кенә сатирик һәм юмористик әсәрләр яза, рус классикларын тәрҗемә итә.

Ә. Исхак – җитмеш елга якын актив иҗат гомерендә зур әдәби мирас калдырган каләм осталарының берсе. Үзе исән чагында аның кырыклап китабы дөнья күрә.

Журналыбызның горурлыгы булган олы әдипне искә алып, укучыларыбызга аның берничә шигырен тәкъдим итәбез.

МӨХӘММӘТ ҺӘМ ТАУ

(Мәсәл)

Бөтен төше
Тозу чималлары белән тулган,
Ләкин район үзәгеннән ерак торган,
Зур гына Тауларның берсе,
Мөхәммәтнең килүен бик озак көткәч,
Көтә-көтә тәмам арып беткәч,
Аның янына
Карар бирде беркөнне үзе барырга.
«Каршысына Тау хәтле Тау баргач,
Һичшиксез, игътибар итми калмас,
Бөтен байлыгымны казытып алыр
Һәм производствога файдаланыр!» –
Дип уйлап ул эченнән генә,
Килеп җитте район үзәгенә.
Ләкин Мөхәммәтнең секретаре
Җибәрмәде аны бусагадан ары.
– Кертә алмыйм, – диде ул аңарга, –
Бүген аның
Үзенә кирәкле тозу чималларын
Үзәктән җибәртүен сорап,
Елап-елап,
Ялвара торган көне Аллага.
Рөхсәт итмәде хәтта күтәргә:
– Андый көнне
Кабул итми ул, – диде, – беркемне.
Килегез сез, – диде, – иртәгә!..
Һәм Тауга, буйсынып секретарьга,
Туры килде акрын гына кайтып китәргә.
Мондый Мөхәммәтләрне
Безнең заманда да хәтта
Очратырга мөмкин әле
Кайбер промкомбинатта.

КУЯН БЕЛӘН АРЫСЛАН

Куян,
Каушап куркуыннан,
Куйган Арысланга ялгышып мат.
Һәм иткән ант
Шахмат уйнамаска икенче кат.

ГЕОМЕТРИК КӨНЛӘҮ

Туры сызык
Түгәрәк сызыктан көнли:
Яшерә, имеш, ул очын
шулкадәр нык, –
Кая яшергәнен һичкем белми!

ЯЛАГАЙ КЕРПЕ

Борчымасын өчен түрәләрнең,
Керпе, парикмахерга кереп,
Тәнендәге барлык энәләрен
Чыккан бөдрәләттереп.

ПӘРДӘ

– Артымда ни барын
Күрсәләр әгәр дә,
Нишләрмен мин? – диеп
Калтырый, ди, Пәрдә.



ХАКЫЙКАТЬ ТӨСЕ

Хакыйкать ул
Асылда
Ап-ак була.
Ана сөте төсле
Саф, пакь була.
Хакыйкатьнең була
Кызылы да,
Канга манчылганда
Көрәш кызуында.
Хакыйкатьнең булмый
Чуары, аласы
Һәм шулай ук булмый
Карасы.
Хакыйкать ул
Асылда
Ап-ак була.
Ана сөте төсле
Саф, пакь була.
Хакыйкатьнең очрый
Кайчак сарысы,
Чагылганда аңарда
Җиңелү сагышы.
Тик саклагыз аны
Пычратудан:
Күгәрә һәм пычрана ул
Тик ятудан!

ЭШЛЕКЛЕ ӘТӘЧ

(Мәсәл)

Бик эшлекләләнеп,
Йөргәндә тиреслектә чуп.ләнеп,
Шундый уй төште Әтәчкә бер көн:
– «Дөньяда, – диде ул, –
Минем кадәр эшлекле кем?
Кем бар миннән дә иртә торучы,
Кычкыручы,
Барлык җан иясен уятучы,
Тавык-чебешләргә азык табучы?
Ә тавыклар –
Ялкау һәм булдыксыз алар:
Ашый торып та гел әзерне,
Күкәйне дә салалар көнгә тик берне.
Чебешләрне дә бит алар
Унарлап кына чыгаралар.
Ышанып булмый аларга бер эшне дә.
Бүгеннән
Үзем чыгара башлыйм чебешне дә,
Башка эшләрне дә үз өстемә алам,
Күкәйне дә үзем салам!..»
Шуннан соң ул
Тавыклар салган йөзләп күкәйне җыеп,
Менеп утырды, барысын бергә өеп.
Хәзер бөтен эш Әтәчнең үз өстендә:
Бер эшкә якын китерми беркемне дә,
Иртүк тора,
Кычкыра,
Тиреслекне казып,
Тавык-чебешләргә эзли азык.
Ул арада шалт-шолт атлап,
Шпорлы аяклары белән таптап,
Күкәйләр өстенә дә менеп ята,
Кайсын сыта,
Кайсын вата,
Үзе һаман кычкыра:
– Кикрикүк тә кикрикүк!
Янәсе, минем эшем бик күп,
Эшләгез сез дә нәкъ минем күк!..
Тавыклар янына барырга вакыты да юк..
Ә үзенең,
Үтүгә карамастан җәй дә,
Салганы юк бер генә күкәй дә,
Исән калган күкәйләр дә бетте бозылып,
Чебешләрнең дә эзе юк!
Андый әтәчләрне
Илтер идем мин базарга
Яки салыр идем казанга.

Җыр канатларында ТИБРӘЛЕП

...Коронавирус. Мин шушы хәтәр чирдән качып, Фәизләр (Зөлкарнәй) белән бергә мүкләп күтәргән Казансу буендагы бакча өемдә йокымсырап ятам. Йолдызларсыз, айсыз, җилле караңгы төн. Елга буенда иркенлеккә туенып үскән биек усак, тирәк кебек агачларның серле шаулавы күңелгә бераз шом сала салуын. Ләкин янәшәдә "Болгар" радиосы булу, аңа көчәеп китәргә ирек бирми. Ул миңа иптәш ролен үти. Әнә Иршат үзе дә биредә кебек. Җырлый да җырлый. Яңа җырыдыр әле. Бүген генә дә әллә ничә тапкыр шуны "әйләндерделәр". Дөресен әйтим, ни сүзләре, ни көе истә калмады. Танылып килүче җырчы югыйсә, әмма алдырып китә алмый, төгәлрәк итеп әйтсәк, күңелгә ярып сала алмый бу җырын. Тегесе шәп менә. Аннары ирле-хатынлылар да, яшьрәк җырчылар да үз сәләтләрен ешрак күрсәтә бирәдә. Тик мин аларның исемнәрен белмим, дөресрәге, истә калдыра алмыйм шул. Күбәйделәр алар. Ярар, җырласыннар әйдә, сәләтләрен үстерсеннәр, бер ачылып китәрләр әле. Шулай атналар, айлар буе кабатлап торсалар, шәт без дә аларның кайберләрен отып кала алырбыз. Әйткәнемчә, "Болгар" радиосы миңа шәп иптәш булып тора, ялгыз гына төн кунганда бигрәк тә, юлчыларга да яхшы юлдаштыр.

Иптәш дигәннән, аларның алып баручылары да бик сәләтле яшь талантлардан тупланган. Аларның һәркайсы турында матур-матур зарисовкалар язып булыр иде. Гөлчәчәкне генә алыйк. Әгәр ул кичке тапшыруларны алып бара калса, ул төнне "йокы күрде юк" инде. Ул шундый тиз сөйли. Аның йөгерек сөйләм теле артыннан фикерләп, әйткән җөмләләренең мәгънә тирәнлегенә төшенеп җитешеп булмый. Кызыксынып тыңлаудан колакларга "ут каба". Никадәр энергия ургылып чыга бу "былбыл"дан, һәр тыңлаучы үзе чамалыйдыр. Төнге уникедә эшен тәмамлап: "Иртәгә чаклы сау булыгыз!" – дип хушлашып киткәч тә, шактый вакыт уйланырга урын калдыра. Кайчакларда без картлар өчен берәр "этлек" тә эшләп куя әле ул (шаяру рәвешендә, әлбәттә), ягъни Иршатлар артыннан берәр ретро җыр кушып җибәрә.

Теге юлы да шулай булды. Бүлмәм бер мизгел эчендә халык көенә охшаган моң белән тулды.

Җил капканы җил ачтымы,
Кемдер керә, кемдер бар...

Сез күз алдына китереп карагыз... төнге уникеләр, караңгы, шомлы көзге төн, җил... һәм урам якта "кемдер бар". Йөрәгең ярылмаса да, котың алынырга мөмкин бит бу очракта. Мин башта аның җыр гына булуын аңышмый тордым. Аннары... торып ук утырдым. Йокы качты. Җыр агыла. Мин тиз генә телефонга (диктофонга) соңгы куплетны яздырып калдырырга өлгерәм. Аннары кабат-кабат шуны тыңлыйм. Тиз генә яндекстан авторларын (Радик Нуретдин, Роза Сәхаветдинова) эзләп табам. Ничек мин аны элегрәк ишетмәдем икән, дим. Әллә хәтерем ялгыша башладымы... Әйтерсең күңелгә "ярып" салдылар бу көйне. Мин хәзер шул көй белән яши башладым, ятсам да торсам да... "...кемдер килә, кемдер бар".

Җыр тексты бер куплетка сыеп бетә торган гап-гади 20 сүздән тора. Ә никадәр тирән мәгънә – өмет, ышаныч хисләре салынган аңа, ә нинди моң, аһәң белән сугарылган ул? Моңа ышану өчен аны бер тапкыр тыңлау да җитәдер.

Ә минем күңел аны меңенче мәртәбә әйләндерә. Инде өченче атнага китте. Коронавирус онытылып, арткы планга күчте кебек. Хәзер мин бу җыр белән авырдым бугай. Янәшәдәге Биектау сырхауханәсенә барып табибка күренимме әллә, дим, тик аны госпитальгә әйләндерделәр. Ашыгыч ярдәм бүлегенә хәбәр итә калсам, температурамны сорарлар дип куркам. Нишләргә соң? Аптырагач, редакциягә шалтыратырга булдым. Трубканы бер ягымлы тавышлы хатын-кыз алды, бик игътибар белән тыңлаганнан соң:

– Аксакал карт Шомбай хәзер өендә генә утыра, редакциягә килеп йөрми. Сезнең сорауларны Алмаз Хәмзинга бирербез, – диде.

Үзе җырчы, үзе композитор, үзе язучы, журналист Алмазетдинның пионер каләмен кара карага манып язган җавап хаты бер көн эчендә үк почта аркылы өйгә килеп җиткән. Улым исә аны шул ук көнне бакчага китереп китте. Күптән, бик күптәннән мондый хатлар алган юк иде. Рәхәт булып китте. Мин башта аның мөһеренә карап, аны озак кына иснәп утырдым. (Коронавирустан саклану чарасы буларак кайберәүләр чүпрәк аркылы аракы да иснәп йөри әле.) Аннары хатны укырга керештем.

– Һе-е-е! – дигән Алмаз абзый, көлгән. Аннары: – Мондый сорауларга тыңлаучы үзе җавап табарга тиеш, – дип өстәгән.

Димәк, мин үз соравыма үзем җавап табарга тиеш булам. Ә ул гади: бернинди шик-шөбһәләргә ышанмыйча яшәргә, тормыш итәргә, сәламәтлегең турында кайгыртырга, саклану чараларын үтәргә. Иң мөһиме шул. Аннары... җыр канатларында тирбәлгән килеш якты уйларыңа ирек куярга... "кемдер бар" кешеңне көтеп, якты киләчәкнең өметле булуына ышанып гомер кичерергә...

Җил капканы җил ачтымы,
Кемдер керә, кемдер бар.
Килер кешем булмаса да,
Кайтыр кешем, кемдер бар.


Мидхәт САДЫЙКОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 12 (1901) декабрь 2020
Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 3.12.2020 ел.
Тираж – 2665 Заказ А-3212
Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Комарлы уеннар нәрсәсе белән куркыныч?

2. Хирург белән сапёрның уртак ягы?

3. Нинди транспорт, кризис булуга карамастан, хуҗасына табыш китерә?

4. Ришвәтне ничек җиңәргә мөмкин?

5. Кайсы әкияттә, самоизоляциядән соң әбисенең өенә ризык китерү тасвирланган?

6. Зурлар өчен пазл?

7. Ватанның бәхет кошы?

ЖАВАПЛАР

1. Башта рәхәтләнеп комарлы уен уйныйсың, ә соңыннан, урамдагы кешеләрдән акча көтеп, гармун уйнап утырасың. 2. Сапёр гомерендә бер генә мәртәбә ялгыша, хирург та сезнең тормышта бер тапкыр гына... 3. Катафалк. 4. Аның өчен гаеплеләрнең арт сабагын укытып кына түгел, шундук җеназасын үткәреп тә. 5. Кызыл Калфак. 6. Суыткычтан алынган әйберләрне шул тәртиптә яңадан урнаштыру. 7. Кыздырылган әтәч.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 11 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«КИНДЕР СУККАНДА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Ф. СӘЛИМҖАНОВА (Тәтеш р-ны, Бакырчы ав.),
Р. МОГЫЙНОВА (Биектау),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Бакырчыдан

Фирая СӘЛИМҖАНОВА!



Виталий ФЕОКТИСТОВ чын мәгънәсендә уникаль кеше иде: архитектор, карикатурачы-рәссам, сатирик, шагыйрь, иллюстратор... Ул – нәшрияттта басылып чыккан әдәби пародияләр китабы авторы да. Виталийның тематика буенча ясалган рәсемнәре журналга үзенчәлек өстәп торды. Аның әсәрләре хәзер дә журнал битләрендә яши. Аларның берничәсен укучыларга тәкъдим итәбез.









4612750670080